| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«28» сентября 2023г. № 151

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 28 декабрендәге 289 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибенә һәм срокларына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясындагы 3.1, 3.2 пунктлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджетның керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга гомуми таләпләрне раслау турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2023 елның 19 июлендәге 09/13-09/3620 номерлы хатын карап, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 28 декабрендәге 289 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибенә һәм срокларының 3 пунктына үзгәреш кертергә, түбәндәге эчтәлекле бәян итеп: «3. Җирле бюджет керемнәренең баш администраторлары Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының Финанс бюджет палатасына норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертелгән көннән соң исемлеккә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр җибәрә. Тәкъдимнәрдә түбәндәгеләр күрсәтелә: - җирле бюджет керемнәренең баш администраторының исеме һәм коды; - җирле бюджет

керемнәренең төр (ярдәмче төр) коды; - җирле бюджет керемнәренең коды исеме; - норматив хокукый актларның реквизитларын күрсәтеп, Исемлеккә үзгәрешләр кертү өчен нигез. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасы тәкъдимнәрне карау йомгаклары буенча алар кергән көннән алып 10 эш көне эчендә Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының исемлеккә үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшли.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Җитәкче И. Х. Хәмидуллин